КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 апрель г.Казань № 272

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июль, 563 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 март, 151 нче; 2020 ел, 26 март, 221 нче; 2020 ел, 16 июнь, 496 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1004 нче; 2021 ел, 13 август, 712 нче; 2021 ел, 4 ноябрь, 1050 нче, 2022 ел, 14 март, 230 нчы, 2022 ел, 28 март, 279 нчы, 2022 ел, 30 сентябрь, 1052 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1491 нче, 2023 ел, 16 март, 258 нче, 2023 ел, 1 август, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип таныргa;

3 пунктчада «фәнни», «дәүләт» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктчага «, шул исәптән балалар һәм яшьләр өчен ял лагерьларында профильле сменаларны оештыру» сүзләрен өстәргә;

8 пунктчада:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль өлкә психологларын һөнәри үстерү һәм аттестацияләү өчен шартлар тудыру;»;

дүртенче абзацта «оешманы» сүзен «оешманы тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип таныргa;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар һәм яшьләр ышаныч телефоннарын оештыру;»;

11 пунктчада «яшьләр арасында» сүзләреннән соң «шулай ук яшьләрне патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар,» сүзләрен өстәргә;

12 пунктчада «тормышка ашыру» сүзләрен «гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктчада «, яшьләр белән эшләү оешмалары эшчәнлеген камилләштерү» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 пунктчага «яшьләр белән эшләү оешмалары эшчәнлеген камилләштерү» сүзләрен өстәргә;

20 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

21 пунктчада «камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү» сүзләрен «алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктчада «кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыра» сүзләрен «кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга, «фараз формалаштыра» сүзләрен «фараз формалаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

30 пунктчада «һәм ведомство максатчан» сүзләрен төшереп калдырырга;

33 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

36 һәм 37 пунктчаларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

44 пунктчада «студентлар» сүзеннән соң «хезмәт» сүзен өстәргә;

56 пунктчада «һәм басма» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 75 һәм 76 пунктчалар өстәргә:

«75) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарын методик яктан тәэмин итү һәм муниципаль берәмлекләр территорияләрендә иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

76) иреклелек (волонтерлык) өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында иреклелекне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына кертү өчен белешмәләр бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин